**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әгерҗе авыл җирлеге Советы карары**

Әгерҗе авылы №139-100 "01" июль 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының 15.12.2021 елның №48-25 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмә хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль хакындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында (25.02.2022 №53-29, 17.06.2022 №64-35, 09.09.2022 №69-37, 26.01.2024 №120-81 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 23 маендагы 637 номерлы карары нигезендә

Әгерҗе авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының 15.12.2021 елның №48-25 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмә хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль хакындагы Нигезләмәгә (25.02.2022 №53-29, 17.06.2022 №64-35, 09.09.2022 №69-37, 26.01.2024 №120-81 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.7.1 пунктында:

а) җиденче абзацта «профилактик визитлар» сүзләреннән соң «, яисә затлар даирәсен билгеләү критерийлары» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасарлары кушуына контроль (күзәтчелек) органы җитәкчесе тарафыннан затлар даирәсен билгеләү критерийлары кертелгән очракта контрольдә тотучы затлар исемлеге раслана, аларга карата профилактик визитлар үткәрелергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Н.Н.Хәсәнов